**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 9 февраль № 76

г. Казань

«Казан – күргәзмә тарихи-мәдәни берләшмәсе» автоном коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында

Тарихи, мәдәни һәм белем бирә торган кыйммәтләрне пропагандалау һәм киләчәк буыннар өчен тарихи һәм мәдәни мирасны саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыятенең «Казан – күргәзмә тарихи-мәдәни берләшмәсе» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына:

«Казан – күргәзмә тарихи-мәдәни берләшмәсе» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючыларның берсе булырга;

«Казан – күргәзмә тарихи-мәдәни берләшмәсе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы уставы проектын эшләргә;

«Казан – күргәзмә тарихи-мәдәни берләшмәсе» автоном коммерциячел булмаган оешмасын төзүгә бәйле башка чаралар үткәрергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\76.doc